*Галиуллин Тәлгат Нәби улы, Сайланма әсәрләр, Казан, 2013, 489-510 нче битләр*

# Шигырь Мәҗнүне
## *(Шагыйрь – мулла-укытучы Равил Сәйфетдин)*

*«Мөгаллим дә, шагыйрь дә булган сәләтле шәхес»*
*Илдар Юзеев*

*1*

Казан дәүләт университетының йөзек кашы, алтын бөртеге кебек кадерле татар теле һәм әдәбияты бүлегендә укучылар арасында Р. Сәйфетдин һәр яктан кабатланмас шәхес иде. Шигырь җене кагылган, матурлык орлыгы салынган Равил гомеренә шигырь Мәҗнүне булып калды.

Равил чегән арбасыннан төшеп калган егет түгел иде. Уртачадан бераз гына калкурак буйлы, тыгыз тәнле, акыллы вә хисчән күзле, куе коңгырт чәчле, сугышта вафат булган Гарәфетдин абзый малае, отличник булмаса да, көчәнмичә, җиңел укыды, дипломын алгач, «язучы булам, Казанда калам» дип чәпчеп йөрмәде, Самара өлкәсенең атаклы Гали авылында ике ел тормыш һәм укыту тәҗрибәсе туплап, туган авылына юл тотты.

Әүвәл ул гади мөгаллим дәрәҗәсендә барлык гуманитар фәннәрне алып бара, аннан соң аны завуч итеп күтәрәләр, у т ы з елга я к ы н күп кенә олы галимнәр биргән мәктәпнең директоры вазифаларын үти. Шул чорда Русиянең мәгар и ф отличнигы, Татарстанның атказанган укытучысы була, СССР мәгариф министрлыгының Мактау Грамотасы белән бүләкләнә, укытучылык, мәктәп белән җитәкчелек эшенең серләре турында мәкаләләр яза. Фидакарь хезмәтенең бу канаты гына да мактауга вә соклануга лаек.

Яше җитеп, укыту эшеннән китеп, беркадәр тын тартканнан (укы: дини белемен күтәргәннән) соң, авыл халкы аны Мулла Иле мәчетенә имам-хатыйб итеп сайлап куя. Шагыйрь-педагог-мулла... Берүк кеше.

Олы вә гыйбрәтле тарихыбызга күз ташласак инанырбыз: язучыларыбызның күбесе муллалар нәселеннән күтәрелгәннәр яисә үзләре дин хезмәтчеләре булганнар. Гали Чокрый, Г. Утыз-Имәни, Мәүла Колый (үзен «Меллагол» дип йөрткән), Акмулла, Г. Кандалый кебек шагыйрьләребез иҗаты, гамәле шуның ачык мисалы.

Студент елларында ук Р. Сәйфетдиннең тикмәгә генә яраткан фәннәре гарәп һәм борынгы төрки-татар телләре булмаган икән, эчке тоемы, намусы чакыруы белән ул үзен дин хезмәтчесе, Корьән серләрен шәрехләүче булырга әзерләгән. Яшәешебезгә, телебезгә инкыйраз янаган XXI гасыр башында дин әһелләре арасында Р. Сәйфетдин кебек олы тормыш мәктәбе узган, татар телен, әдәби мирасыбызны бөтен нечкәлекләре белән тойган, милләтенең яшәеше өчен җан атып йөргән фидаиләр күбрәк булырга тиеш дип уйлыйм. Ошбу һөнәргә кәсеп итеп караган, вәгазьне башка телдә алып барган муллалардан Батырша, Морад кебек көрәшчеләр чыкмаячак.

Сүз уңаенда шуны да искәртеп үтик: аның иң сөймәгән кешеләре – бер төрле сөйләп, икенче төрле эшләгән, яшәгән, аң үсешләрендә артта калган дин әһелләре.

*Надан муллаларың утыра түрдә,*
*Коръәнне дә бозып аңлатып,*
*Тамакларын кырып, башны иеп,*
*Буш сүз чәйнәп, хөсет таратып.*
*Күзләрендә – минлек сукырлыгы,*
*Телләрендә – сәүдә хәйләсе.*
(«Вәисиләр турында хикәят»)

Ошбу юлларда Тукай сатирасына хас үтергеч тәнкыйть йогынтысын сиземләү өчен әдәбият белгече булуың да кирәк түгел. Уртак аһәң, көлү күз алдында.

2

Иҗатының беренче чорын тәшкил иткән, студент елларында язылган шигырьләренең үзәгендә дөнья бизәкләренә мәхәббәт, сөю-сөелү белән сынау, «аның» килүен көтү, юксыну, шикләнү... Лирик геройның мәгъшукасы Көнчыгышның Зөһрә, Ләйлә кебек чибәрләреннән һич кенә дә ким түгел.

Син янасың тиңсез йолдыз булып,
Җырланмаган җырым иясе.
---------------------------------------------
Сине үбә зәңгәр күк кояшы
Дала җиле сыйпый кадерләп.
(«Син янасың...», 1959)
Сине усал һәм тәкәббер диләр,
Артык горур диеп сөйлиләр.
(«Сине усал...», 1959)

«Мәңгелек кыз» шигыренә иркәләнеп чытыкланулары, үзен иркен-ирекле тотуы белән Такташның Алсуы килеп кергәндәй була.

*Ул кызыйга һәркем үлеп гашыйк,*
*Әллә ние белән сөйдерә.*
*Ул үзе дә барсын – яшен-картын*
*Коча-үбә, уйлап тормый шартын,*
*Чәчәк биреп китә – исертә,*
*Йөрәкләргә серле көч кертә.*
(«Мәңгелек кыз», 1959)

Алдагы елларда шагыйрь «Мәхәббәт», «Кулларың», «Студент кызга», «Есениннан», «Күл буенда» (1960-1961) кебек бөтен барлыгын биләгән сөю хисен, мәхәббәтне олылаган, бу олуг тойгының ямен, тәмен, исен җаны аша уздырган әсәрләрен иҗат итә. Гүзәлен назлы, иң матур сынландыруларга күмгәннән, шикләнү-көнләшүләрен җиңгәннән соң, мондый нәтиҗәгә килә:

*Син тормышның үзе кебек чибәр,*
*Үзе кебек чуар гүзәлем.*
(«Сине усал...»)

Күңел түрен киң каерып ачып кергән олы мәхәббәте белән бер чорда аның шигъри фикерләве үсешенә тәэсир ясаган я н ә бер вакыйгага була. Ул – Туфанны «таба». «1956 елның октябрендә Казанның Тукай клубында сөекле шагыйребез Хәсән Туфан белән очрашу

кичәсе булды. Мин дә, университетның беренче курсында укучы 18 яшьлек егет, шыгрым тулы залга керә алдым... Шагыйрь үзенә генә хас сузынкы, моңлы бер көй белән бик күп шигырьләрен укыды. Бу төнне мин йокысыз үткәрдем. Нинди илаһи кешебез бар икән безнен», – дип яза ул «Олуг шагыйрь турында истәлекләрем» мәкаләсендә. Туфан белән турыдан-туры очрашуы Казанның 89 нчы татар мәктәбендә педпрактика узганда була (1960). 1964 нче елның салкын декабрь аенда Мулла Иленә очрашуга килгән язучылар төркемен Хәсән абый да бизи. Туфан, Яшел Үзәннән авылга кайтканда, Равилгә карап тора да:

– Мин сезне, егет, кайдадыр бер күргән идем шикелле.

– Сезгә үзегезнең укучыларыгызны танып бетерү мөмкин түгел, Туфан абый. Шулай да берзаман мин сезнең алда бер шигырь укыган идем.

– Казандагы татар мәктәбендәме? Кытай яшьләре дә килгән иде. Мине боз каплаган елга белән чагыштырган идегез... Язасызмы соң хәзер дә?

– Язгалыйм. Кайчак басылып та чыккалыйм.

– Гафу итегез, фамилиягезне белмим.

Мин фамилиямне әйткәч, Туфан мине шаккаттырды:

– Сезне бит мин укып барам.

Шунда шагыйрь минем «Күл буенда» дигән шигыремнән ике строфаны яттан укып та биргәч, мин тәмам югалып калдым, – дип искә ала Равил шул ук язмасында.

Йөгерек вәзенле, кызның шаян, иркә холкын үзәккә алган «Күл буенда» шигыре бер укуда истә-ятта калырлык.

Күл буенда шук Оркыя
Ташка басып кер уа.
Күлдә йөзгән ак казларны
Бер чакыра, бер куа.

Һәр шигъри, яңарак табышка игътибарлы Туфан, бәлки, «Көн көлдеме – кояш шары күлгә төшеп ватыла» метафорасын, яисә «Күлгә баккач, кара күзләр Бер кысыла, бер тула», дигән яшьлек ялкыны бөркелеп торган юлларны хәтер казанына алгандыр.

Р. Сәйфетдин Х. Туфанга тирән эчтәлекле, символик мәгънәле, шигырьне бер җепкә тезгән үзәк образлы *«Балачакта* миңа кешеләр» (1960) әсәрен багышлый. Ул олуг шагыйребезне «Шифа бирә торган саф сулы елга»га, боз астында сулкылдап яткан тирән агымга тиңли дә, киңрәк нәтиҗә ясап, Туфан шигъриятендә шаулап аккан гомер елгасы чагылышын күрә.

*Үтте еллар, яңа яз килде,*
*Боз кузгалды, елга елмайды.*
*Көзгесенә күк зәңгәрлеген,*
*Кояш алсулыгын ул алды.*
(«Балачакта миңа кешеләр»)

3

*Туган* авылында мөгаллимлек эшенә, шук балалар, һәркайсы үзен тиешле бәясен алмаган шәхес санаган укытучылар дөньясына кереп чумып, гаиләдә балалар үстерү мәшәкатьләре өстенә өелеп төшкәч, шигърияте дә күзгә күренеп үзгәрә.

*Соң килдең син миңа, Акыл,*
*Кайда йөрдең яшь чакта?*
*Синнән башка мине йөрәк*

*Тилертте төрле якка.*
*Соң килдең син миңа, Акыл,*
*Рәшәләр кая киткән?*
*Алсу, алсу дигәннәрем*
*Алсу булмаган икән.*

***

*Кеше җирнең бөтен матурлыгын*
*Үзенә җыйган бөек баласы.*
*Ул – тән генә, матди генә түгел,*
*Шуңа кыен кеше буласы.*
(«Кеше – бөек», 1969)

***

*Кеше үзе белми*
*Ак биләүле чагын.*
*Ак кәфенле чагын*
*Белми кала тагын.*

***

*Вакыт ага күзгә күренмичә,*
*Ага галәм аша, йолдызларның*
*Берсен кабызып, берсен сүндереп,*
*Вакыт ага таулар аша,*
*Вакыт ага минем тәнем аша.*
(«Вакыт ага». 2002)

Укытучы булып эшләү дәверендә шагыйрь әдәп-әхлак, тәрбияви-мәгърифәти мәсьәләләрне күбрәк игътибар үзегенә алса, («Ялган шөһрәт белән түгел», «Алтын көзем», «Хатын-кызларга», «Ир уртасы – җәй уртасы»), җитмешенче еллар башында мәктәп директоры вазифаларын үти башлагач, покосны киңрәк алдырып, халкының, туган телебезнең язмышы турында ешрак уйлана, үзен киләчәгебез өчен җаваплы кешеләрнең берсе итеп күрә. («Бу бит – безнең тарих», «Син дөньяга кеше өчен килгән», «Туган телем», «Татар мәктәбе»). Фәлсәфи агым, галәм серләрен аңлауга омтылыш көчәя.

*Чиксез икәнен дә беләм, ләкин,*
*Хәйран калып чикнең югына.*
*Уем оча гел җитәргә теләп*
*Чиксезлекнең теге ягына.*
(«Чиксезлек»)

*Иң ямьле, матур, күркәм чагыштыруларны, метафораларны шагыйрь туган табигать яшәешеннән таба, иленә, халкына, якыннарына мәхәббәтен җиткерүнең яңадан-яңа юлларын эзли. Шәкли нисбәттән аның бер шигыре дә икенчесен кабатламый дисәк тә, зур хата булмастыр.*

*Шаянланып янсын шаян күз –*
*Яшел урман төшеп чумган күл.*
*(«Йөрәгемдә тамыр җәйгән...»)*
*Кичке күктә кызыл шәфәкъ яна,*

*Елга өсләренә ут капкан.*
*(«Кичке күктә...»)*
*Караңгылык качты яңадан –*
*Ай елмаеп җиргә карады.*
*(«Кояш батты...»)*

*Табигатьнең матурлыгын, эчке яшәешен, җанлы, тәнле итеп сурәтләүдә Равил гаҗәеп кызыклы күзәтүләр, ачышлар ясый.*

*Тын бакчада бер яшь каен үсә.*
*Толымнары туза җил чыкса.*
*Чын әкият сөйләп яфраклары*
*Юаталар күңелең ялыкса.*
*(«Тын бакчада...»)*

*Кеше кичерешенең, холык-менәзенең мең төрле борылышларын чагылдырырга омтылу аны психологик анализ мөмкинлекләрен иркенрәк «эшкә җигү» юлына алып чыга.*

*Бул шәфкатьсез, таш бул миңа, зинһар,*
*Миңа карап алай елмайма,*
*Ул үзе дә сөя икән дигән*
*Алдануга миңа юл куйма.*
*(«Миңа һаман да син усал кара»)*

4

XX гасыр ахырында, яңа дәвер башында Р. Сәйфетдин иҗатында тарихилык, ерак үткән белән бүгенге арасында якынлыкны аңларга омтылу рухы көчәя.

*Атлантида, Атлантида*
*Әллә чын, әллә ялган.*
*Шаһит булып ул чаклардан*
*Ай калган, кояш калган.*
*Безнең гомер – Атлантида*
*Айкалыр да чайкалыр.*
*Бездән шаһит булып бары*
*Кояш калыр, ай калыр.*
(«Атлантида», 2001)

Р. Сәйфетдиннең шигъри фикерләвендә Вәисиләр кебек бөек шәхесләрне биргән туган төбәге белән горурлану хисе, олыгайган саен, зуррак урын ала («Мин бит Мулла Иле баласы»).

Чыгышлары белән Мулла Иленнән, яңа бер иҗтимагый, сәяси, дини юнәлешкә нигез салган аталы-уллы Баһаветдин һәм Гайнаннар аның рухи дөньясында, иҗатында аерым урын билиләр.

Р. Сәйфетдин бу юнәлешкә ике язмасын: «Вәисиләр турында хикәят» (2000) исемле күләмле шигъри әсәрен һәм «Мине игелекле мөселман дип санавыгызны үтенәм» исемле хикәясен багышлый.

Р. Сәйфетдин шагыйрь Баһаветдиннең Петербург подвалларында югалып калган яшендәй ялкынлы хатларының эчтәлеген хәзерге укучыга җиткерү зарурияттен аңлап эш итә.

*«Галиҗәнап патша хәзрәтләре!*

*Хак сагында торган хөкемдар.*
*Татарларың хөрлек өмет итә,*
*Татарларга нигә урын тар?»*
*Алдагы юлларда бу фикер яңадан кабатлана.*
*«Рәхимең киң, изгелекләр эшлә.*
*Татарларның моңа хакы бар».*
(«Вәисиләр турында хикәят»)

Халкына тиешле ташламалар таләп итүе өчен Баһаветдин ишан хакимиятнең явыз дошманына әверелә. Җегәрле, пырдымсыз кешедән котылу әмәле дә табыла. «Акча өчен антны» саткан табиблар аны юләрләр йортына ябып куялар. Шагыйрь бу гаделсезлекне Баһаветдинның үзеннән «фаш иттерә».

*Тикшерегез!*
*Мондый шигырьләрне*
*Юләр кеше яза аламы?*
*Бөтен Казан буйлап өне китте:*
*– Хаклык уты җирдә янамы ?*

Вәисиләрнең көрәшләре эзсез югалмаган, аларның хыял-идеяләре олы шәхесләрне рухландырган.

*Толстой да белгән Мулла Илен,*
*Кунак иткән сөеп Гайнанын.*
*Хәтта Ганди белеп Һиндстанда*
*Горур йөрткән Сардар байрагын.*

*Хаклык өчен җанын биргәннәрнең*
*Белерләрме кадрен бер заман?*
*Аһ, белсәләр кадрен газизләрнең*
*Булыр иде төзек бу җиһан!*

Атасы нигез салган Вәисиләр хәрәкәтен улы Гайнан дәвам иттерә. 16 яшендә төрмә белән куркытып алуларына карамастан, ул сынмый, сыгылмый, корыч кебек нык көрәшче булып җитешә һәм сайлаган юлының, гамәлләренең дөреслеген тикшерү, киңәшләшү нияте белән акыл иясе, мәшһүр язучы Л. Толстойга мөрәҗәгать итә. Р. Сәйфетдин «Мине игелекле мөселман дип санавыгызны үтенәм» хикәясен шул тарихи очрашуга багышлый. Ошбу вакыйганы үзе шаһиты булган кешедәй бәян итә.

Яңа гасыр башында Р. Сәйфетдинның Тукай мирасы белән Ислам диненең җәмгыять, халык тормышына тәэсире турында җитди уйлануы шигъри аңының яңа югарылыкка күтәрелүен тәэмин итә. Аның ышануынча, «Тукайсыз иман, вөҗдан, әхлак тулы була алмас беркайчан». 2004 елда «Мин яшимен Тукай дөньясында» шигырен язып чыкса, 2006 сәнәдә «Тугры Тукай» исемле күләмле публицистик поэмасын иҗат итә.

Тукай кабызган милли рухны, азатлык өчен көрәш байрагын кулдан төшермәсә генә татар милләте, «гүзәл Тукай теле, Ватан теле» мәңге яшәячәк дигән фикер поэманың лейтмотивын тәшкил итә.

*Тукай җаны Әлмисактан Гали,*
*Пәйгамбәрне ничек сынаса,*
*Тукаен да тәңре шулай йөрткән*
*Мең газаплы авыр юл аша.*
*Тугры калган шагыйрьТәңрегә*
*Сөелүдә калган мәңгегә.*
(«Тугры Тукай»)

Тукай аның өчен шагыйрьлек, туган халкыңа, намусыңа тугрылык идеалы, кулына каләм алып, сүзе белән халкына чыккан һәр шагыйрьгә аның таләбе югары. Үлчәү бизмәне – Тукай намусы.

*Куркак кеше шагыйрь булса – бәла,*
*Кизәнә ул мифик дошманга.*
*Тукайның бит һәрбер аткан угы*
*Барып тигән мәгълүм бер җанга.*
(«Тугры Тукай»)

Тукай шәхесенең, васыятьләренең рухын аңларга омтылу аны, табигый рәвештә, ислам диненең сафлыгы, җаныбызга, тәнебезгә, ышанычыбызга иңдергән сихәте турында уйлануларга, фәлсәфи-әхлакый нәтиҗәләргә алып килә.

Дин нигезләрен, аның туу, таралу тарихын шәрехләүгә, ислам диненең үзенчәлекләрен ачуга Р. Сәйфетдин тулы бер Гөләндәмен багышлый. «Аксакал монологы» *(2005),* «Иртәнге дога» *(2006),* «Иман нуры» *(2009),* «Пәйгамбәрдән килгән сәхабәләр» *(2010)* һ.б.

Ислам диненең нигезләрен, Коръәннең иңүен, пәйгамбәрләр тарихын шигъри телдә ачып биргән әсәрләре Р. Сәйфетдиннең, авыз тутырып әйтәм, хәтта хәзерге шигъриятебезнең суфичылык тәгълиматын яңа чор таләпләреннән чыгып дәвам иткән казанышы саналырга лаеклы.

Шагыйрь «Иртәнге дога» әсәрендә Ходайдан тарихи хаталарыбыз, сөннәр, һуннар, болгарлар чорында ясалган надан-җаһил гамәлләребез өчен ярлыкау сорый, инде яклаучысын, саклаучысын ислам динендә тапкан адәм баласына иң катгый таләпләр белән килә. Юк, шагыйрь-мулла һич кенә дә шәхси мәнфәгатьләре турында кайгыртмый, ул Раббыбыздан татар кавеменә кыяматкәчә инкыйразга ирек кыйлмавын сорый, һәр адәм баласына җан тынычлыгы бирүдә мәрхәмәтеннән ташламавын үтенә.

*Коткар Ходам, татарымны,*
*Аермагыл Иманыңнан*
*Җирдәге һәр кеше җанын*
*Яраткансың үз нурыңнан.*
(«Иртәнге дога»)

Тарихилык аһәңе, фәлсәфи-дини юнәлеше белән «Иртәнге дога» Тукайның «Кичке азан», С. Сүнчәләйнең «Азан» кебек мәгълүм шигырьләрен хәтерләтеп куя, аларның лаеклы дәвамы кебек кабул ителә. «Мин пәйгамбәр түгел...» робагыенда ул адәми затка иң югары таләпләр белән килә.

*Мин пәйгамбәр түгел, гади зат дип,*
*Гөнаһларны аклау кирәкме:*
*Һәр гади зат булсын пәйгамбәрдәй*

*Ак күңелле керсез йөрәкле.*

Дингә хезмәт итүгә алынган затлар, бигрәк тә вәгазь укыганда, халык белән очрашуларда Р. Сәйфетдиннең югары кимәлле дини-фәлсәфи шигырьләренә таянырга тиешләр дип уйлыйм. Аларны аерым китапчык итеп чыгарып, мәчетләргә, мәдрәсәләргә таратсалар да, изге гамәл булыр иде.

Р. Сәйфетдин китабының шактый өлешен алып торган прозасы аерым сөйләшүгә лаек. Гайнан Вәисинең Л. Толстой янына баруын сурәтләгән хикәясендә ул кешенең *к и* леш-килбәтен сурәтләүгә, диалоглар коруга осталыгын күрсәтсә, авылдашларына, шаян укучыларына, тормыштан алынган мәзәк хәлләргә, сәеррәк кешеләргә багышланган истәлек хикәяләрендә, этюдларында ул барыбер шагыйрь булып кала. «Алма» хикәясендә ул безнең якларда үсә торган җимешнең тәмен, исен, «чыраен» И. Бунинның «Антоновские яблоки» әсәреннән һич кенә дә кайтыш сурәтләми, Тормыш фаҗигасен үзәккә алу ягыннан Равил язмасы тетрәндерә. Абыйсы укучыларын алма рәсемен ясарга өйрәтә дә сугышка китә. Ул ясаган өч рәсем генә саклана, «...абыйның гомере бик иртә – шау чәчәк чагында сугыш кырында өзелеп калган.

Кеше дөньядан китә. Аннары ул яшәвен исәннәр күңелендә дәвам итә. Укытучы абыем минем хәтеремдә матурлык сурәте, нәфислек чагылышы булып яши, күңелемә хуш ис тулы мәңгелек көзге сафлык бөркеп тора».

Ул бернәрсәне дә уйлап чыгармый, үзе яхшы белгән, күргән, үз башыннан узган тормыш материалларына гына таянып яза.

А. Хәлим Мөдәррис Вәлиевкә багышланган мәкаләсен («К.У.», 2013, №6) мин Р. Сәйфетдин турында әйтергә җыенган сүзләр белән башлап китә:«Миңа бу язмамны язуы ифрат рәхәт. Ләззәтле халәттә эрим. Чөнки язасы кешем – сүзендә үзенә тиң гамәл иясе. Милләтебезгә ифрат та мөһим һәм саваплы гамәлләр кыйлган зат».

Авыл мәктәбен яшәтүгә зур көч куйган Р. Сәйфетдиннең гомер һәм рух җимешен – «Мулла Иле моңнары» җыентыгын мин «ләззәтле халәттә» укыдым һәм, хәлдин килгәнчә, аңа бәя бирергә, укучыны әлегәчә тиешле бәясен алмаган шагыйрь иҗаты белән таныштырырга тырыштым.

2013